

Мордовиядә Россия Федерациясенен эчке эшләр бvлеге хезмәткәре конен тантаналы рәвештә билгеләп vттек. Бу олкәгә гомерләрен багышлаган эчке эшләр хезмәткәрләре династиясенен берсе турында.
Рәсим Рәхмәтулла улы Курмаев, Мордовия ГИБДДда 34 ел подполковник булырак эшләгән Шамиль абыйсы vрнәгендә, милициягә хезмәткә урнаша. 1983нче ел. Тормыш тәҗрибәсе булган перспективалы кешеләр бе-лән милиция сафын ныгыткан чак. Шул вакытка Рәсим Кызылбайраклы Тонъяк флотында хезмәт итеп кайткан, комсомол эшләре буенча партия мәктәбен тәмамлаган була. Башта Рәсим Рәхмәтулла улы укыту-тәрбия бирv эшләре буенча 14 номерлы СПТУ директоры урынбасары буларак эшкә урнаша. Кvнеле хыялында булган милиция хезмәтенә тарта. Максатын тормышка ашыру теләге белән, Саранск милиция мәктәбендә оч айлык курсларны тәмамлый ул, ә соныннан Ләмберәдә участковыйларнын олкән инспекторы вазыйфасын vти башлый. Участок полиция вәкилләренен хезмәте һәрчак мәшәкатьле, тынгысыз, чонки ул тормыш уртасында кайнап, кешеләр белән тыгыз аралашып эшли. Бу хезмәт, кайда гына булуына карамастан, бик катлаулы һәм кvпкырлы. Шулай да жанын-тәнен биреп хезмәт биографиясен башлап жибәрә Рәсим Рәхмәтулла улы. Жин сызганып эшли. Ләмберә районы халкы Кырви авылында туып-vскән тырыш, булдыклы Курмаевка «Анискин» дигән исем дә кушалар. Теге Михаил Жаровнын «Анискин и Фантомас» фильмында тосле. Биографиясеннән бер факт. Рәсимнен әнисе, Саядят Хәсән кызы, улына Ләмберәдә квартир биргәч беренче тапкыр килгәндә, адресы буенча тvгел, ә шул «Аниськин» кушаматы буенча кайда яшәгәнен табып ала. Тормышта әнә шундый очраклар да була.
Белгәнебезчә, участковый вазыйфасы четерекле; полиция кешесе vзендә кvпторле унай сыйфатлар булдырырга тиеш. Мәсәлән, мал-туар комплексында, мәдәният йортында, мәктәпләрдә еш булырга кирәк, шулай ул халыкнын тормышын, яшәv vзенчәлекләрен, кем нәрсәгә сәләтле икәнен белеп эш-ләргә тиеш. Бу мәгълумат жинаять итvчеләрнен эзенә тошәргә, жинаятьне ачарга ярдәм итә. Участковый кондез һәм тонлә, эштә һәм ойдә чакта да халык белән аралашып яшәргә тиеш була. Курмаев Рәсим райондашларын һәрвакыт полициянен игътибар vзәгендә тота. Сvзләремә дәлил. Шулай, Ләмберәдә яшәvче Н.И.Максимова иптәш ана: «Тонлә абзардан vгеземне урлаганнар», - ди елап. Бу вакыт Рәсим Рәхмәтулла улы участок инспекторлары бvлеген житәкли. Сойләгәннәрне исәпкә алып, хайванны алып киткән юлдагы эзләре буенча барырга карарга килә. Шулай, жинаят эшләрне эзләv житәкчесе Шамиль Няим улы Кадикин белән буталчык

юллар белән алып барган жинаятьче артыннан Пензятка авылына кадәр житәләр, халыктан сораштырып vгез белән жинаятьчене табалар.  Ул – Максимованын кvршесе булып чыга. Тугзанынчы елларда шундый урлаулар кvп иде, ди язма героебыз; халыкнын мал-туары, Александровка, Кривозерье, Аксеново колхозлары фермалары каракларда еш интекте.
- Жинаять эшләре буенча житәкче Шамиль Няим улы Кадикин белән каты тырышырга, кvп хезмәт куярга туры килде шул вакытларда, - дип искә ала Рәсим Рәхмәтулла улы корреспондент  Николай Дюжевка биргән интервьюсында. - Жинаять эшләрен ачарга жинел булмаса да, аларны таба идек. Шулай, Аверьянов группасынын жинаять эшләрен – малларны урманчыкларга алып барып суюлары һәм рынокта итләрен сатуларын ачтык. Караклар группасында берсенен аерым ойрәтелгән овчарка токымлы эте малларны читтә куып, котеп торган каракларга алып бара, икән. Шуна да жинаятьне ачу кыенга туры килгән иде, әмма без эзләренә тоштек, ди.
Киресенчә, жинаятьчеләрнен гомер-ләрен vлемнән коткарган очраклары да булган аларнын. 2002нче ел. Саловка авылы. Яна ел алдыннан бу авыл кешесе Ләмберә РОВДысы оператив дежур частенә бер йорттан охотниклар мылтыгы,  кинжал, песец тун, аудиовидеоаппаратура, компьютер урлануы турында хәбәр итә. Тиз арада подполковник Рәсим Курмаев, оператив группа белән, жинаять урынына житә. Эзләр кырга алып бара, ә тыштагы кочле буран эзләрне юа. Шундый табиги шартларда, урланган әйберләрне ташлап барган эздән барырга, милиционерга ярдәм кирәк була. Игорь Янинга ярдәм очен кайтырга дигән морәжәгать була. Ә Курмаев белән Волков тонге буранда эзләvне дәвам иттергәннәр. Берничә километр vткәч, алар аудиоаппаратуранын кочәйткечен табалар. Озакламый буранда алга атлаган жинаятьчеләрне кvреп «Стой!» дип кычкырып югарыга аталар. Караклар карга егылалар. Алар кулыннан милиционерлар кинжал һәм мылтыкны алалар. Жинаятьчеләр тунганнар һәм арыганнар, икән. Рәсим Курмаев икесе белән кала, ә Волковы калган каракларны эзләп китә. Тонге сәгать оч. Рәсим бу салкында озак калсалар, тунып vләчәкләрен анлый һәм яшь каракларны, урлаган әйберләре белән бергә, артынан сойрәп коч-хәл белән Хутор Лопатино авылына житә. Шунда Волков алга качып киткән тагы ике каракны тоткан. Менә шундый хезмәтләре аларнын.
Бvген эчке эшләр сафында Курма-евларнын балалары эшли. Альбина Шамиль кызы - полиция майоры, ә Гульнара Рәсим кызы - полиция капитаны (Управление по охране общественного порядка МВД по РМ). Рәсим Рәхмәтулла улы Курмаев, МВДдыдан киткәч, III класслы хокvмәт кинәшчесе Ләмберә суды администраторы булып эшли. Ә оныгы Динияр, бабасы Рәсим тосле, полициядә хезмәт итәргә хыяллана.
Шамиль Рәхмәтулла улы Курмаев (рәсемдә сулдан унга), Гульнара Рәсим кызы Янгличева, Рәсим Рәхмәтулла улы Курмаев. Уртада - анын оныгы Динияр.

**Наилә Насырова**